# КАРАР

**“21” ноябрь 2019 ел№ 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Иске Кишет авылында юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау (Күпер урамы);
- Иске Кишет авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Иске Кишет авылында агачларны санитар кисү;
- Иске Кишет авылында янгын гидранты алу һәм урнаштыру, 1 данә .

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 289 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 170 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 170 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл

җирлеге Яңа Кишет авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыенынәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Иске Кишет авылында юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау (Күпер урамы);
- Иске Кишет авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Иске Кишет авылында агачларны санитар кисү;
- Иске Кишет авылында янгын гидранты алу һәм урнаштыру, 1 данә .

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов